# ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

2026 елда гражданнарга үзара салым кертү турында
Поповка авыл җирлегенең Яңа Нәлим торак пунктында
Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы

**2025 елның 18 ноябрендәге** **1 номерлы**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 06.10.2003 елгы 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 28.07.2004 елгы 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Зәй муниципаль районы Поповка авыл җирлегенең Яңа Нәлим торак пунктында гражданнар җыены нигезендә Татарстан Республикасы

**Карар кылдым:**

1. 2026 елда Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Поповка авыл җирлегенең Яңа Нәлим торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешедән, көндезге формада укучы студентлардан, I төркем инвалидлардан, ялгыз өлкән яшьтәге гражданнардан, Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә мобилизация буенча чакырылган гражданнардан тыш, 600 (алты йөз) сум күләмендә үзара салым кертергә.

2. Алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтергә:

- торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияткә ия автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту (торак пункт эчендә юл салу (20-40 фр вак таш сибү, 400 марка гомуми файдаланудагы җирле әһәмияткә ия автомобиль юлларына һәм Үзәк урам буенча торак пункт чикләрендә вак таш сибү (чокырларны ремонтлау)

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Поповка авыл җирлегенең Яңа Нәлим авылы мәгълүмат стендларында урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә, Зәй муниципаль районының рәсми сайтында «авыл җирлекләре» бүлегендә бастырып чыгарырга, «Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталы» нда урнаштырырга (PRAVO.TATARSTAN.RU) кабул ителгән көннән алып 7 көн дәвамында (Поповка авыл җирлеге Уставының 69 п.5 ст.).

Гражданнар җыенында рәислек итүче
Поповка авыл җирлеге башлыгы
Зәй муниципаль районы ____________ (имза) О.М. Юнусова (имзаның шифрын ачу)